**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘТӘС АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
423737, Әтәс авылы,
Үзәк ур., 75а нчы йорты.
Тел.3-44-66

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423737, село Атясево,
ул. Центральная,дом 75а,
Тел. 3-44-66

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

1 ноябрь 2019 ел

№1

Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Әтәс авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Әтәс авыл җирлеге башлыгы **Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегендәге Әтәс, Апач, Чирү авылларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 14 ноябренә билгеләргә.
2. Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегендәге Чат, Иске Бикчәнтәй, Чынык авылларында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 15 ноябренә билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне распарга:
- су челтәрләрен ремонтлау, тоту, су чыганакларын лицензияләү;
-урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)
-йорт төзелеше һәм ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;;
- зират коймасын ремонтлау;
- Күму урыннарын документаль рәсмиләштерү;
-рәсми спорт һәм мәдәни чараларны оештыру һәм уздыру;;
- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү Әтәс, Апач авылларында;
- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү, обелиск төзү;;
- Иске Бикчәнтәй авылындагы ФАП бинасында су белән тәэмин итү һәм чокырны төзекләндерү;;
- гидротехник корылмаларга декларацион тикшерү үткәрү Чат һәм Чирү авылларында

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Халык җыенын 2019 елның 14 ноябрь көнне түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Әтәс авылы, Үзәк урамы,75а йорты. 2019 елның 15 ноябрь көнне түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Бикчәнтәй авылы, Г. Тукай урамы, 3 нче йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Чат авылы, Үзәк урам, 43 нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Әтәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Әтәс авыл җирлеге башлыгы: Э.Ф.Насыйрова